Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге
Кибәк Иле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

22 октябрь, 2022 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлегенең Кибәк Иле торак пунктында 2022 елның 22 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 165 (йөз алтмыш биш).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 97 (туксан җиде).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми саны 97 (туксан җиде).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми саны 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2023 елда Кибәк Иле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем, 2 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- балалар мәйданчыгы төзү

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кибәк Иле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Кибәк Иле авыл җирлеге башлыгы Р.А. Сәйфетдинов